**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**" 17 " июнь 2019 ел №99**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 14 ноябрендәге "Җир салымы турында»гы 54 нче карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Советының 2017 елның 14 ноябрендәге «Җир салымы турында" гы 54 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

   1.1. 6 статьяның икенче абзацындагы «1 ноябрьгә кадәр» сүзләрен «31 декабрьдән дә соңга калмыйча»сүзләренә алмаштырырга;
   1.2. 2 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
   «3. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук «гражданнар үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,23%;».
2. Әлеге карарның 1.2 пункты рәсми басылып чыккан көненнән бер ай узгач, әмма 2020 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк булмаган вакыт узгач үз көченә керә.
3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

   1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы Корэле авылы,Үзәк ур., 2а;
   2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Варварино авылы, Ленин урамы, 32; һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге” башлыгы, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге” Советы рәисе Р.Т.Нотфуллин